**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
ЧЕРЕМШАНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел.+7(84396) 4-35-10 тел./факс +7(84396) 4-35-09, email: Ispolkom.Cheremshan@tatar.ru; http://cheremshan.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

21.11.2025 года **Чирмешән авылы** № 360

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының «Муниципаль милектәге җир кишәрлеген гражданнар милкенә (арендага) дача хуҗалыгы алып бару өчен бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2020 елның 17 декабрендәге 522 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Җир кодексына һәм «Россия Федерациясе Җир кодексына үзгәрешләр кертү һәм «Россия Федерациясе Җир кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 34 статьясындагы 7 өлешенең үз көчен югалтуын тану хакында» Федераль законның 3 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 28 декабрендәге 538-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының «Муниципаль милектәге җир кишәрлеген гражданнар милкенә (арендага) дача хуҗалыгы алып бару өчен бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2020 елның 17 декабрендәге 522 номерлы карарына (17.06.2021, №240 үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.9 пунктта:

- 3 абзацны яңа редакциядә бәян итәргә: «Вәкаләтле орган түбәндәге нигезләрнең берсе генә булса да җир кишәрлеген бирүне алдан килештерүдән баш тарту турында карар кабул итә:

1) җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү турындагы гаризага кушып бирелгән җир кишәрлегенең урнашу схемасы Җир кодексының 11_10 статьясындагы 16 пунктында күрсәтелгән нигезләр буенча раслана алмый;

2) төзелергә тиешле җир кишәрлеге мөрәҗәгать итүчегә Җир кодексының 39_16 статьясындагы 1-13, 14_1-19, 22 һәм 23 бүлекләрендә күрсәтелгән нигезләр буенча бирелә алмый;

3) чикләре «Күчемсез мөлкәтне дәүләт теркәвенә алу турында» Федераль закон нигезендә төгәлләштерелергә тиешле җир кишәрлеге мөрәҗәгать итүчегә Җир кодексының 39_16 статьясындагы 1-23 пунктчаларында күрсәтелгән нигезләр буенча бирелә алмый.».

- 7 абзацны яңа редакциядә бәян итәргә: «Вәкаләтле орган дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлеген түбәндәге нигезләрнең берсе булса да торглар үткәрмичә бирүдән баш тарту турында карар кабул итә:

1) җир кишәрлеген бирү турында гариза белән җир законнары нигезендә торглар уздырмыйча җир кишәрлеге сатып алырга хокукы булмаган зат мөрәҗәгать иткән;

2) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану, түләүсез файдалану, гомерлек мирас итеп биләү яисә аренда хокукында бирелгән, моңа җир кишәрлеген бирү турындагы гариза белән әлеге хокукларга ия зат мөрәҗәгать иткән яисә Җир кодексының 39_10 статьясындагы 2 пунктының 10 пунктчасы нигезендә җир кишәрлеген бирү турында гариза бирелгән очраклар керми;

3) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге бакчачылык яисә коммерциягә карамаган яшелчәчелек ширкәтенә бирелгән җир кишәрлеген бүлү нәтиҗәсендә барлыкка килгән, моңа мондый гариза белән әлеге ширкәт әгъзасының (әгәр мондый җир кишәрлеге бакчачылык яисә яшелчәчелек өчен булса) яисә коммерциягә карамаган бакчачылык яисә яшелчәчелек ширкәтендә катнашу (әгъзалык) хокукына ия булмаган, федераль законнар, Россия Федерациясе субъектлары законнары нигезендә җир кишәрлеген беренче чиратта яисә чираттан тыш сатып алуга йә Җир кодексының 39_18 статьясы нигезендә җир кишәрлеге сатып алуга хокукы булган граждан мөрәҗәгать иткән очраклар керми (әгәр мондый җир кишәрлеге бакчачылык кишәрлеге булса), шулай ук гражданнар үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык яисә яшелчәчелек алып барган территория чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләре милекчеләреннән тыш (әгәр җир кишәрлеге гомуми билгеләнештәге җир кишәрлеге булса);

4) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегендә гражданнарныкы яки юридик затларныкы булган бина, корылма, тәмамланмаган төзелеш объекты урнашкан, моңа җир кишәрлегендә сервитут, гавами сервитут нигезендә урнаштыру рөхсәт ителә торган корылмалар (шул исәптән төзелеше тәмамланмаган корылмалар) яки Җир кодексының 39_36 статьясы нигезендә урнаштырылган объектлар урнашкан очраклар керми, йә җир кишәрлеге бирү турындагы гариза белән әлеге биналарның, корылмаларның, андагы бүлмәләрнең, төзелеп бетмәгән әлеге объект милекчесе мөрәҗәгать иткән булса, шулай ук әгәр җир кишәрлеге бирү турында гариза бирелгән һәм анда урнашкан биналарга, корылмаларга, төзелеп бетмәгән объектка карата ирекле төзелешне сүтү турында йә ирекле төзелешне сүтү яисә аны билгеләнгән таләпләргә туры китерү турында карар кабул ителгән булса һәм күрсәтелгән карарлар белән билгеләнгән срокларда

Россия Федерациясе шәһәр төзелеше кодексының 55_32 статьясындагы 11 өлеше каралган бурычлар үтәлмәгән очраклар керми;

5) җир кишәрлеген бирү турында күрсәтелгән гаризада дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге бина, корылма, тәмамланмаган төзелеш объекты урнашкан, моңа җир кишәрлегендә сервитут, гавами сервитут нигезендә урнаштыру рөхсәт ителә торган корылмалар (шул исәптән төзелеше тәмамланмаган корылмалар) яисә Җир кодексының 39_36 статьясы нигезендә урнаштырылган объектлар урнашкан очраклар керми, йә җир кишәрлеге бирү турындагы гариза белән әлеге биналарның, корылмаларның, алардагы бүлмәләрнең, төзелеп бетмәгән әлеге объект хокук иясе мөрәҗәгать иткән очраклар керми;

6) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге әйләнештән алынган яисә әйләнештә чикләнгән була һәм аны бирү җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән хокукта рөхсәт ителми;

7) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге, мөрәҗәгать итүче җир кишәрлеген милеккә бирү турындагы гариза белән, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга яисә җир кишәрлеген арендага бирү турындагы гариза белән, җир кишәрлеген резервлау турындагы карарның гамәлдә булу вакытыннан артыграк вакытка мөрәҗәгать иткән очракта, дәүләт яисә муниципаль ихтыяҗлар өчен резервланган була, моңа җир кишәрлеген резервлау максатлары өчен бирү очраклары керми;

8) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә башка зат белән төзелгән йә аны комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән территория чикләрендә урнашкан, әгәр әлеге карарны гамәлгә ашыру өчен территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзү таләп ителмәсә, моңа җир кишәрлеген бирү турындагы гариза белән мондый җир кишәрлегендә урнашкан бинаның, корылманың, андагы биналарның, төзелеп бетмәгән объектның милекчесе, яисә мондый җир кишәрлегенең хокук иясе мөрәҗәгать иткән очраклар керми;

9) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә башка зат белән төзелгән йә аны комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән территория чикләрендә урнашкан, әгәр күрсәтелгән карарны гамәлгә ашыру өчен территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзү таләп ителмәсә яисә җир кишәрлеге территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә башка зат белән төзелгән җир кишәрлегеннән төзелгән булса, моңа мондый җир кишәрлеге федераль әһәмияттәге объектларны, региональ әһәмияттәге объектларны яисә җирле әһәмияттәге объектларны урнаштыру өчен билгеләнгән һәм мондый җир кишәрлеген бирү турында гариза белән күрсәтелгән объектларны төзүгә вәкаләтле зат мөрәҗәгать иткән очраклар керми;

10) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзелгән җир кишәрлегеннән төзелгән йә, күрсәтелгән карарны гамәлгә ашыру өчен территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзү таләп ителмәгән очракта, аны комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән территория чикләрендә урнашкан һәм территорияне

планлаштыру буенча расланган документлар нигезендә федераль әһәмияттәге объектларны, региональ әһәмияттәге объектларны яисә җирле әһәмияттәге объектларны урнаштыру өчен билгеләнгән, моңа җир кишәрлеген арендага бирү турында гариза белән территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзелгән зат мөрәҗәгать иткән очраклар керми, ул әлеге затның күрсәтелгән объектларны төзү буенча йөкләмәсен күздә тота;

11) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге аукцион предметы була, аны уздыру турында хәбәр итү Җир кодексының 39_11 статьясындагы 19 пункты нигезендә урнаштырылган;

12) аны бирү турында гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенә карата Җир кодексының 39_11 статьясындагы 4 пунктының 6 пунктчасында каралган аны сату буенча аукцион яисә аны арендалау шартнамәсе төзү хокукына аукцион уздыру турында гариза керде, мондый җир кишәрлеге Җир кодексының 39_11 статьясындагы 4 пунктының 4 пунктчасы нигезендә төзелгән булса һәм вәкаләтле орган тарафыннан Җир кодексының 39_11 статьясындагы 8 пунктында каралган нигезләр буенча әлеге аукционны үткәрүдән баш тарту турында карар кабул ителмәде;

13) аны бирү турында гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенә карата Җир кодексының 39_18 статьясындагы 1 пунктының 1 пунктчасы нигезендә индивидуаль торак төзелеше, торак пунктлар чикләрендә шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык алып бару өчен җир кишәрлеге бирү турында хәбәрнамә урнаштырылган;

14) җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегеннән файдалану максатларына туры килми, моңа территорияне планлаштыруның расланган проекты нигезендә линия объектын урнаштыру очраклары керми;

14_1) сорала торган җир кишәрлеге тулысынча территориядән файдалануның махсус шартлары булган зона чикләрендә урнашкан, андагы җир кишәрлекләреннән файдалануга билгеләнгән чикләүләр җир кишәрлеген файдалануның җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән максатларына ярашлы рәвештә җир кишәрлегеннән файдалануга юл куймый;

15) Җир кодексының 39_10 статьясындагы 2 пунктының 10 пунктчасы нигезендә җир кишәрлеге бирү турында гариза бирелгән очракта, сорала торган җир кишәрлеге Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә оборона һәм иминлек ихтыяҗлары өчен бирелгән һәм күрсәтелгән ихтыяҗлар өчен вакытлыча файдаланылмый торган җир кишәрлекләре исемлегенә кертелмәгән;

16) коммерциягә карамаган бакчачылык яисә яшелчәчелек ширкәтенә җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенең мәйданы Җир кодексының 39_10 статьясындагы 6 пунктында билгеләнгән күләмнән артып китә;

17) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге расланган территориаль планлаштыру документлары һәм (яисә) территорияне планлаштыру документлары нигезендә федераль әһәмияттәге объектларны, региональ әһәмияттәге объектларны яисә җирле әһәмияттәге объектларны

урнаштыру өчен билгеләнгән һәм җир кишәрлеген бирү турындагы гариза белән әлеге объектларны төзүгә вәкаләтләре булмаган зат мөрәҗәгать иткән;

18) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге Россия Федерациясе дәүләт программасы, Россия Федерациясе субъектының дәүләт программасы нигезендә бинаны, корылманы урнаштыру өчен каралган һәм җир кишәрлеге бирү турындагы гариза белән әлеге биналарны, корылмаларны төзүгә вәкаләте булмаган зат мөрәҗәгать иткән;

19) җир кишәрлеген хокукларның белдерелгән төрендә бирү рөхсәт ителми;

20) гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенә карата рөхсәт ителгән файдалану төре билгеләнмәгән;

21) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге билгеле бер җир категориясенә кертелмәгән;

22) гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенә карата аны бирүне алдан килештерү турында карар кабул ителде, аның гамәлдә булу вакыты чыкмады, һәм җир кишәрлеген бирү турындагы гариза белән әлеге карарда күрсәтелмәгән башка зат мөрәҗәгать итте;

23) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге дәүләт яисә муниципаль ихтыяҗлар өчен тартып алынган һәм гаризада күрсәтелгән мондый җир кишәрлеген бирү максаты мондый җир кишәрлеге тартып алынган максатларга туры килми, мондый җир кишәрлегендә урнашкан күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиеш дип тануга бәйле рәвештә дәүләт яисә муниципаль ихтыяҗлар өчен тартып алынган җир кишәрлекләреннән тыш;

24) аны бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенең чикләре «Күчемсез мөлкәтне дәүләт теркәвенә алу турында» Федераль закон нигезендә төгәлләштерелергә тиеш;

25) аны бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенең мәйданы җир кишәрлегенең урнашу схемасында, территорияне межалау проектында яисә урман кишәрлекләренең проект документациясендә күрсәтелгән мәйданнан ун процентттан артыгракка зуррак була;

26) «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясындагы 4 өлешендә каралган дәүләт мөлкәте исемлегенә яисә муниципаль мөлкәт исемлегенә кертелгән җир кишәрлеген бирү турындагы гариза белән кече яисә урта эшкуарлык субъекты булмаган зат яисә 209-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы 3 өлеш нигезендә аңа карата ярдәм күрсәтелә алмаган зат мөрәҗәгать иткән».

- 13 пунктчасында «бастырып чыгарылган һәм» сүзләрен төшереп калдырырга, «бакчачылык» сүзен «гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык алып бару» сүзләренә алмаштырырга.

1.2. 5 бүлекне яңа редакциядә бәян итәргә: «мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның, муниципаль хезмәтне күрсәтүче органның, дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның яки муниципаль хезмәтне күрсәтүче органның вазыйфаи затының, йә дәүләт яисә муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, шулай ук 210-ФЗ номерлы Федераль

законның 16 статьясындагы 1_1 өлешендә каралган оешмаларның яисә аларның хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерүе

Мөрәҗәгать итүче шикаять белән түбәндәге очракларда да мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гарызнамәне, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 15_1 статьясында күрсәтелгән гарызнамәне теркәү срогын бозу;

2) дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтү срогын бозу. Күрсәтелгән очракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү мөмкин, әгәр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1_3 өлешендә билгеләнгән тәртиптә тиешле дәүләт яисә муниципаль хезмәтләрне тулы күләмдә күрсәтү функциясе йөкләнгән булса;

3) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда тапшырылуы яисә гамәлгә ашырылуы каралмаган документлар яисә мәгълүматны йә гамәлләрне башкаруны таләп итү;

4) мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актларында, дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен муниципаль хокукый актларда каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) әгәр баш тарту нигезләре федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектларының законнарында һәм башка норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган булса, дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту. Күрсәтелгән очракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү мөмкин, әгәр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1_3 өлешендә билгеләнгән тәртиптә тиешле дәүләт яисә муниципаль хезмәтләрне тулы күләмдә күрсәтү функциясе йөкләнгән булса;

6) дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган түләү таләп итү;

7) дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның яисә муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1_1 өлешендә каралган оешмалар яисә аларның хезмәткәрләре тарафыннан дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы опечаткаларны һәм хаталарны төзәтүдән

баш тартуы йә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакытын бозу. Күрсәтелгән очракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү мөмкин, әгәр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1_3 өлешендә билгеләнгән тәртиптә тиешле дәүләт яисә муниципаль хезмәтләрне тулы күләмдә күрсәтү функциясе йөкләнгән булса;

8) дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү срогын яисә тәртибен бозу;

9) федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектларының законнарында һәм башка норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда туктатып тору нигезләре каралмаган булса, дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору. Күрсәтелгән очракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү мөмкин, әгәр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1_3 өлешендә билгеләнгән тәртиптә тиешле дәүләт яисә муниципаль хезмәтләрне тулы күләмдә күрсәтү функциясе йөкләнгән булса;

10) әлеге Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен яисә дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәткәндә кирәкле документларны кабул итүдән беренче тапкыр баш тартканда аларның булмавы һәм (яисә) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документларны яисә мәгълүматны дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән таләп итү. Күрсәтелгән очракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү мөмкин, әгәр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1_3 өлешендә билгеләнгән тәртиптә тиешле дәүләт яисә муниципаль хезмәтләрне тулы күләмдә күрсәтү функциясе йөкләнгән булса;

Шикаять бирү һәм карау тәртибенә гомуми таләпләр

1. Шикаять язма рәвештә кәгазьдә, электрон рәвештә дәүләт хезмәтен күрсәтүче органга яисә муниципаль хезмәтне күрсәтүче органга, күпфункцияле үзәккә яисә күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючы (алга таба-күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючы) булган тиешле гавами - хокукый берәмлекнең дәүләт хакимияте органына (җирле үзидарә органына), шулай ук 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1_1 өлешендә каралган оешмаларга тапшырыла. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган яки муниципаль хезмәт күрсәтүче орган җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата

шикаятьләр югарырак органга (ул булганда) бирелә йә ул булмаган очракта турыдан-туры дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган яки муниципаль хезмәт күрсәтүче орган җитәкчесе тарафыннан карала. Күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр әлеге күпфункцияле үзәк җитәкчесенә бирелә. Күпфункцияле үзәкнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючыга яисә Россия Федерациясе субъектының норматив хокукый акты белән вәкаләт бирелгән вазыйфаи затка бирелә. 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1_1 өлешендә каралган оешмалар хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр әлеге оешмаларның җитәкчеләренә бирелә.

2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның йә муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи заты, дәүләт яисә муниципаль хезмәткәр, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган йә муниципаль хезмәт күрсәтүче орган җитәкчесе карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять почта аша, күпфункцияле үзәк аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның рәсми сайты, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның рәсми сайты, бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы йә региональ дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин. Күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять почта, "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, күпфункцияле үзәкнең рәсми сайтыннан, бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең региональ порталыннан файдаланып, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин. 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1_1 өлешендә каралган оешмаларның, шулай ук аларның хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять почта, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, әлеге оешмаларның рәсми сайтларыннан, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталыннан йә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең региональ порталыннан файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин.

3. Федераль башкарма хакимият органнарының, дәүләт корпорацияләренең һәм аларның вазыйфаи затларының, федераль дәүләт хезмәткәрләренең, Россия Федерациясе бюджеттан тыш дәүләт фондларының вазыйфаи затларының, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1_1 өлешендә каралган оешмаларның һәм аларның хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр бирү һәм карау тәртибе, шулай ук күпфункцияле үзәк, аның хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр бирү һәм карау тәртибе Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.

3_1. Федераль законда дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнарның, муниципаль хезмәтләрне күрсәтүче органнарның, дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче

органнарның яки муниципаль хезмәтләрне күрсәтүче органнарның вазыйфаи затларының, йә дәүләт яисә муниципаль хезмәткәрләрнең күрсәтелгән шикаятьләрне бирүгә һәм карауга бәйле мөнәсәбәтләр өчен карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр бирү һәм карау тәртибе (процедурасы) федераль закон белән билгеләнгән очракта, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 11_1 статьялары һәм әлеге статьяның нормалары кулланылмый.

3_2. Дәүләт хезмәтләре күрсәтүче органнарның, муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнарның, дәүләт хезмәтләре күрсәтүче органнарның яки муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнарның вазыйфаи затларының йә шәһәр төзелеше мөнәсәбәтләре субъектлары булган юридик затларга һәм индивидуаль эшкуарларга карата, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 6 статьясындагы 2 өлеше нигезендә расланган төзелеш өлкәләрендәге процедураларның тулы исемлекләренә кертелгән процедураларны гамәлгә ашырганда дәүләт яисә муниципаль хезмәткәрләрнең карарларына һәм (яисә) гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять мондый затлар тарафыннан әлеге статьяда билгеләнгән тәртиптә йә Россия Федерациясенең монополиягә каршы законнарында билгеләнгән тәртиптә монополиягә каршы органга тапшырылырга мөмкин.

4. Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарының һәм аларның вазыйфаи затларының, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарының дәүләт граждан хезмәткәрләренең, җирле үзидарә органнарының һәм аларның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына), шулай ук күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр бирү һәм карау үзенчәлекләре тиешенчә Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актлары һәм муниципаль хокукый актлар белән билгеләнә.

5. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүмат булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелә торган дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның яисә муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи заты йә дәүләт яисә муниципаль хезмәткәр, күпфункцияле үзәк, аның җитәкчесе һәм (яисә) хезмәткәре, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1_1 өлешендә каралган оешмалар, аларның җитәкчеләре һәм (яисә) хезмәткәрләре исеме;

2) мөрәҗәгать итүченең - физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булган очракта), яшәү урыны турында белешмәләр йә мөрәҗәгать итүченең - юридик затның исеме, булган урыны турында белешмәләр, шулай ук контакт телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы;

3) дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның, муниципаль хезмәтне күрсәтүче органның, дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның яисә муниципаль хезмәтне

күрсәтүче органның вазыйфаи затының йә дәүләт яисә муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1_1 өлешендә каралган оешмаларның, аларның хезмәткәрләренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында белешмәләр;

4) мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның яки муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи заты йә дәүләт яисә муниципаль хезмәткәр, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре, Федераль законның 16 статьясындагы 1_1 өлешендә каралган оешмаларның, аларның хезмәткәрләренең карары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән килешми торган дәлилләр. Мөрәҗәгать итүче дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) йә аларның күчермәләрен тапшырырга мөмкин.

6. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органга, муниципаль хезмәт күрсәтүче органга, күпфункцияле үзәккә, күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючыга, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1_1 өлешендә каралган оешмаларга йә югарырак органга (булган очракта) кергән шикаять аны теркәгән көннән алып унбиш эш көне эчендә каралырга тиеш, ә мөрәҗәгать итүчедән документлар кабул итүдән йә җибәрелгән опечаткаларны һәм хаталарны төзәтүдән дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның, муниципаль хезмәтне күрсәтүче органның, күпфункцияле үзәкнең, әлеге Федераль законның 16 статьясындагы 1_1 өлешендә каралган оешмаларның баш тартуына шикаять белдерү яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозган өчен шикаять бирелгән очракта - аны теркәгән көннән алып биш эш көне дәвамында.

7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны юкка чыгару, дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән опечаткаларны һәм хаталарны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә алына торган Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган акчаларны кире кайтару рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.

8. Әлеге статьяның 7 өлешендә күрсәтелгән карар кабул ителгән көннең иртәгесеннән дә соңга калмыйча мөрәҗәгать итүчегә язма рәвештә һәм мөрәҗәгать итүченең теләге буенча шикаятьне карау нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап электрон рәвештә җибәрелә.

8_1. Шикаять әлеге статьяның 8 өлешендә күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчегә җавапта канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган, күпфункцияле үзәк йә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1_1 өлешендә каралган оешма тарафыннан дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәткәндә ачыкланган хокук бозуларны кичекмәстән бетерү максатларында гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенә

һәм мөрәҗәгать итүчегә дәүләт яисә муниципаль хезмәт алу максатларында башкарылырга тиешле алдагы гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

8_2. Шикаять әлеге статьяның 8 өлешендә күрсәтелгән җавапта канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип танылган очракта, кабул ителгән карарның сәбәпләре турында дәлилле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

9. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яисә җинаять составы билгеләре ачыкланган очракта, әлеге статьяның 1 өлеше нигезендә шикаятьләрне карау вәкаләтләре бирелгән вазыйфаи зат, хезмәткәр булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрәләр.

10. Әлеге Федераль законның дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә гражданнарның һәм оешмаларның хокуклары бозылуга карата шикаятьләрне карау тәртибен билгели торган нигезләмәләре «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон белән җайга салына торган мөнәсәбәтләргә кагылмый.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисенә йөкләргә.

Район Башкарма комитеты
җитәкчесе                                                                 И.М.Җамалетдинов